**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 15 октябрендәге 3518 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Идел буе районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 25 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:070118:957;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы, Подаметьевская урамы;

- билгеләү максаты: электр челтәре хуҗалыгы объектын – җирле әһәмияттәге БКТП-58 блоклы комплектлы трансформатор подстанциясен эксплуатацияләү;

- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, БКТП-58 җирле әһәмияттәге трансформатор подстанциясенә милек хокукы (2008 елның 11 октябрендәге 16-АА 816113 номерлы) теркәлгән.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә

ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Сервитутны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарга 2 номерлы кушымтадан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чykканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү буенча эшләр тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аңардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 15 октябрендәге
3518 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре**




| Масштаб 1:250<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (проектлана торган) |
| 16:50:070118 | кадастр кварталы |
| 16:50:070118:957 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

---